# Нәсыйхәт

җомга
27
май 2011
№ 4

**Рәхимле вә Шәфкатьле АЛЛАҺ исеме белән**
**Мамадыш мәдрәсәсенең айлык дини-иҗтимагый газетасы**


# БЕРЕНЧЕ КАРЛЫГАЧЛАР



**Язның иң матур айларының берсе май аедыр. 5нче май көнне дә кояш, күңелләрне сөендереп, нурларын җир йөзенә сирпеде.**

Бу көнне мәдрәсәдә өч ел буе гыйлем алучы хатын-кызлар чыгарылыш имтиханнарын тапшырды... Болар иң гүзәл, иң тырыш, акыллы ханымнардыр. Аларның мәдрәсәгә йөреп өч ел укулары бушка үтмәде. Алар Коръән-Кәрим китабын дөрес уку серләренә төшенеп, пәйгамбәребез с.г.в.нең тормышы, хәдисләре белән танышып, фикх, гакыйдә, гарәп теле кебек фәннәрне өйрәнделәр. Шушы кыска гына өч ел эчендә, Аллаһының иң бөек Китабын кулга алып, дөрес итеп укырга өйрәнү иң зур бәхет түгелме соң?

Бу күркәм ханымнар арасында иң хөрмәтлеләре: Аллаһының динен, Китабын укырга өйрәним дип, карлы бураннарда, яңгырлы, салкын көннәрдә, авыллардан, дистәләрчә чакрымнар узып килүчеләр. Бу-яшьләре 70тән узган ак яулыклы әбиләребездер. Алар арасында Хәлиуллина Зөбәйрә, Габидуллина Гамилә, Әүхадиева Рашидә, Фәизова Рәйсә, Ямалиева Суфия, Закирова Фәүзия, Рәхимуллина Вәсилә кебек абыстайлар. Алар пәйгамбәребез с.г.в.нең "Бишектән алып, ләхеткә кадәр гыйлем ал" дигән хәдисенә туры килергә тырышалар. Уку дәверендә башкалардан артта калмыйча, зур тырышлык белән гыйлем дөньясында йөзеп, үзләренең изге ният-максатларын тормышка ашыралар. Әлбәттә, уку бер кайда да җиңел булмый. Юкка гына халыкта: "Гыйлем алу – энә белән кое казу",- димәгәннәрдер. Гыйлем алу зур тырышлыкны гына түгел, ә гамәлдә дә, нияттә дә ихлас булуны таләп итүче гыйбадәттер. Ә һәр гыйбадәт, бары тик Аллаһы ризалыгы өчен генә, ихлас күңелдән үтәлергә тиеш. Чөнки ихлас булсак кына, безнең гамәлләребез кабул булачак. Ихлас булган очракта гына, безнең гыйлем, мәчет-мәдрәсәгә йөрүебез дөньяда да, ахирәттә дә безгә файда китерәчәк. Шуның өчен, ничә яшьтә булуыбызга, нинди генә зур изгелекләр кылуыбызга карамастан, гыйлемнәребез һәм гамәлләребез файда китерсен дисәк, ихлас булырга тырышыйк. Пәйгамбәребез с.г.в.нең бер хәдисендә гыйлем хакында "Бер кеше гыйлем эстәү нияте белән юлга чыкса, Аллаһы аңа җәннәт юлын җиңел кылыр. Гыйлем эстәүче кеше риза булсын өчен, фәрештәләр канатларын куеп торырлар (хөрмәт күрсәтерләр). Гыйлем эстәүче кеше өчен күктә вә җирдә булганнар, хәтта судагы балыклар да истигъфар кылырлар,"- диелә. Бөтен галәмгә җибәрелгән рәсүл, пәйгамбәребез с.г.в.нең сүзләре - Аллаһы Тәгаләнең вәгъдәсе- безнең өчен иң кыйммәтле сүзләр. Аллаһы Тәгалә һәрберләребезгә саулык-сәламәтлек, иминлек биреп, гыйлем чишмәләребезне тутырып, бәхет-сәгадәттә яшәргә насыйп итсен.

***ЯРУЛЛИНА ВЕНЕРА,***
***мөгаллимә.***

# Яңалыклар

Бөек Җиңүнең 66 еллыгы уңаеннан Мамадыш мәдрәсәсе шәкертләре, мөгаллимнәре шәһәребезнең сугыш ветераннары белән очраштылар. Алар мөселман яшьләренә үзләренең үгет-нәсыйхәтләрен бирделәр. Тыныч тормышта яшәүнең кадерен белергә чакырдылар. Очрашу азагында ветераннарга чәй эчертү оештырылды һәм истәлекле бүләкләр тапшырылды.

***

Шәкертләр һәм мөгаллимнәр Кирмәнчек шәһәрчегенең төзелеш һәм реставрация корылмаларында булдылар. Чарада Урта Кирмән урта мәктәбе укытучысы Ринат әфәнде Хәйруллин да катнашты. Ул бу урыннарның тарихы белән таныштырды. Чара азагында бергәләшеп табигать кочагында ял иттеләр, пылау белән сыйландылар. Сәяхәт уңышлы һәм файдалы булды.

***

Мамадыш мәдрәсәсе яңа уку елына шәкертләр туплый башлады. Бу көннәрдә мөгаллимнәр авылларга сәфәр чыгып, мәктәпләрнең тугызынчы сыйныф укучылары белән очраша, аларга мәдрәсә тормышы турында сөйли, укырга чакыра. Мөселманнарны Аллаһка табынып яшәргә өйрәтү, дини белем дәрәҗәсен күтәрү, районыбызда белемле, дәрәҗәле имамнар, Ислам нигезләренә өйрәтүче укытучылар һәм башка дин белгечләрен әзерләү – төп максат.

***

Шәкертләр татар зыяраты җирен җыештырдылар. Бу эшкә алар үз ниятләре белән алынды. Чараны оештыручы мәдрәсә директоры Габдрахман Хәбибуллин: «Ислам кануннарын, тарихны теоретик рәвештә генә өйрәтү дөрес булмас, яшьләр үз куллары, эшләре белән моңа якынаерга тиеш. Шул очракта ул тарихка, әби-бабаларыбызның батырлыгына, каһарманлыгына башкача караячак»,– диде.

# ӘБҮ ХӘНИФӘ МӘЗҺӘБЕН ӨЙРӘНИК

**Бөтен дөнья мөселманнары яңа меңъеллык алдыннан замандашларның каршылыгына очрады: әһле ислам яшәгән илләрдә дини экстремизм һәм кискен хәрәкәт итү (радикализм) вирусы җибәрелде. Алар вөҗдан иреге гамәленең яңа рәвешләрен барлыкка китерде.**

Бүген күп илләрнең рухи мохитен төрле деструктив агымнар чолгап алды. Шуңа күрә татар зыялылары, дәүләт вәкилләре белән берлектә үткәрелгән дин эшлеклеләренең тарихи җыенында мөселманнар арасында килеп туган хәлгә борчылу белдерелде. Анда мондый хәлдән чыгуның бер ысулы итеп эшләрне Әбү Хәнифә калдырган юнәлештә, ягъни хәнәфи мәзһәбендә алып баруның зарурлыгы турында әйтелде. Ул Россия мөселманнарының күпчелегендә дини тормышның нигезе итеп алынды.

Хәнәфи мәзһәбе нәрсәне аңлата?

Ислам динендә ул нинди урын тота? Тарихка мөрәҗәгать итсәк, Әбү Хәнифә (699-767) дигән исем алган Ногман ибн Сабит данлыклы фикһ белгече булган. Аның исеменә әл-Имам әл-Әгъзам (Бөек Имам) дәрәҗәле титулы кушылган. Әбү Хәнифә сөнниләр мәзһәбенә нигез салган имамнарның иң өлкәне иде. Бу имамнар арасыннан фәкать Әбү Хәнифә генә Мөхәммәд Пәйгамбәрнең (с. г. в.) сәхабәләре белән очрашкан. Әбү Хәнифәнең варис булуы мәсьәләсенә шуның өчен дә зур әһәмият бирелә: ул заманның күренекле фикһ галимнәре әл – Әузаи, Суфьян әс-Саури, Ләис ибн Саад, Мәлик ибн Әнәс аның дәрәҗәсенә дәгъва кыла алмадылар. Болардан тыш, Әбү Хәнифә көндәлек тормыш таләпләренә җавап бирә торган Коръән һәм сөннәткә нигезләнеп, мөселманнарның хокук системасын эшләгән беренче илаһият белгече. Нәкъ әнә шуңа күрә имам әш-Шәфигый: “Мөселманнар фикһтагы уңышлары өчен Әбү Хәнифәгә бурычлы”, – дигән. Дөрестән дә, Әбү Хәнифәгә кадәр фикһ дигән фән булмаган. Ул истихсан (хәерлесен өстен күрү) һәм кыяс (Коръән белән хәдискә таянып хөкем чыгару) ысулларын барлыкка китерде. Имам шәригать галимнәрен акыл һәм гаделлек юлы белән хөкем итәргә чакырды.

Имамның никадәрле бөек галим булуын әле бүгенгә кадәр бәяләп бетерү мөмкин түгел. Әбү Хәнифәнең алымы аның мәзһәбен тормыш шартларына нык якынайта. Бары Әбү Хәнифәгә генә Әл-Имам Әл-Әгъзам дигән исем бирелүе һәм мөҗтаһид-мотлак (алар шәригатьтәге һәр сорауга мөстәкыйль рәвештә фәтва чыгара алганнар) дәрәҗәсенә ирешкән укучыларының булуы күп нәрсәләр хакында сөйли. Башка мәзһәбләргә нигез салган имамнардан аермалы буларак, бары Әбү Хәнифәгә җәмгыятьтә үзгәрешләр барган чорда үзенең фәтваларын чыгарырга туры килгән. Шуңа күрә дә хәнәфи мәзһәбе исламдагы иң түземле хокук мәктәбенә әйләнгән. Акылга нигезләнеп гамәл кылудан тыш, хәнәфи мәзһәбенең түземле булуына, Аллаһка бөтен калебең белән ихластан ышанып, сүз белән иман кәлимәсен әйтү дә тәэсир итәдер. Мөселманнар өммәте арасында таркалыш китереп чыгарырга сәләтле күп санлы бер-берсенә каршы килүче сектант төркемнәр барлыкка килгәнгә күрә дә хәнәфи мәзһәбе оешуга нигез салган. Бу мәктәпнең төп кагыйдәләре ислам белемен ала алмаган һәм шәригатьне тулысынча үтәмәгән миллионнарча кешеләрне дә Аллаһка ышанучы итеп караудан тыймый. Ул хәтта җирле инсаннарга исламга кадәрге иске йолаларны сакларга да комачауламый. Алар хәнәфи мәзһәбендә хокукның өстәмә чыганаклары дип танылa. Шуңа күрә гади мөселманнар да бу мәзһәбне үзләренә аңлаешлы дип таный. Моннан исә Урта Азия, Алтын Урда, Госманлы дәүләтендә һәм Бөек Магуллар империясендә кешеләрнең хәнәфи мәзһәбен кабул итүләре шул сәбәптән икәнлеге ачыклана. Аларның нәселе хәзергә хәтле бу мәзһәбтә булуын дәвам итә.

Хәнәфи мәзһәбендәге фикер хөрлеге нәтиҗәсендә Фәраби һәм Әбугалисина кебек дөнья күләмендәге галимнәр барлыкка килә. Аларның фәнгә керткән өлеше бәһаләп бетергесез. Кешелек дөньясына укымышлы, мәдәниятле һәм рәхим-шәфкатьле затларның кирәк булуы бәхәссез. Бу көчләрнең барысы да мәзһәбләрдә тупланган. Әбү Хәнифә зыялы кеше буларак, ислам дине өндәгән әдәп-әхлак кагыйдәләрен үзенә алган. Ул мондый очракларда чагылыш тапкан.

Бөек имам төннәрен гыйбадәттә үткәргән. Әбү Йосыфның хәбәр итүенчә, ул һәр төнне бер рәкәгатьтә тулысынча Коръәнне укып чыккан. Кайчакларда төнге һәм иртәнге намазларны бер тәһарәт алу белән укыган. Бервакыт бер кеше имамга: “Алладан курык”, – дигән. Бу сүзләрдән соң, Әбү Хәнифә калтырап китте, агарынды һәм башын аска иеп: “Сиңа Аллаһының рәхмәте булсын! Кешеләр бу сүзләрне ишетүгә никадәрле мохтаҗлык кичерә!” – диде.

Әбү Хәнифә үз заманының иң абруйлы дин белгече булган. Шәддад ибн Хәким аның турында: “Мин ул заманда аңа караганда да гыйлемлерәк кешене күрмәдем”, – дигән. Имам әш-Шәфигый: ”Кешеләр хокук фәнен Әбү Хәнифәдән өйрәнә” һәм “Кешеләр хокук фәнендә Әбү Хәнифә белән чагыштырганда балалар кебек кенә”,-дип белдергән.

Әбү Йосыф хәбәр иткәнчә, Әбү Хәнифә бервакыт төшендә Мөхәммәд Пәйгамбәрнең (с.г.в.) каберен казып, аның сөякләрен җыйганлыгы турында күрүен сөйләгән. Бу төш аркасында ул нык кына куркуга калган. Аннары дусты Ибн Сириннән аңа аңлатма бирүен сораган. Ибн Сирин: ”Син Аллаһ илчесенең сөннәтен җыеп, шуңа җан өрә торган кеше”, – дигән. Тик Россия мөселманнары арасында хәнәфи мәзһәбе киң таралган булса да, Әбү Хәнифәнең карашлары һәм эшләү алымнары киң җәмәгатьчелеккә тулысынча билгеле түгел. Шуңа күрә бүгенге көндә Әбү Хәнифәнең дини мирасын өйрәнү аеруча мөһим гамәл булып тора. Безгә шуны аңлау мәслихәт: радикаль (кискен) идеологияне кайбер илләрдә һәм төбәкләрдәге кебек, бездә көч кулланып юкка чыгару мөмкин түгел. Биредә аңа шундый шартлар тудыру зарури: бу идеологиягә ихтыяҗ барлыкка килмәсен һәм ул үз-үзен юкка чыгарсын. Ә исламның хәнәфи мәзһәбендә кискен идеологиягә урын юк. Кайбер экспертларның: “Хәнәфи мәзһәбе радикализмны тоткарлап торучы көч”, – дигән сүзләрендә хаклык бар. Бу мәктәп кешеләргә түземле һәм уртача караштa булуы белән аерылып тора. Шуны онытырга ярамый: динне акыл белән кабул иткәндә генә без Раббыбыз чакырган урталыкка ирешә алырбыз.

*ГАБДРАХМАН ХӘЗРӘТ ХӘБИБУЛЛИН.*

**«Әй, иман китергән бәндәләр! Аллаһыга итәгать итегез һәм Пәйгамбәргә итәгать итегез! Шулай ук, сезнең арадагы Коръән белән гамәл кылып, Коръән дәлилләре белән әмер итүче хакимгә итәгать итегез!» (“Ниса”сүрәсе, 59аять).**

# Җаныма тынычлык табам

**Мин бәлагә юлыгып, могҗиза белән генә исән калдым. Бик авыр вакытларымда, Аллаһы Тәгаләнең барлыгына, берлегенә ышанып, Аңа ялвардым: "Балаларым хакына гомер бирсәң иде!"–дидем.**

Ярдәменнән ташламады, бик зур авырлыклар белән булса да, аякка бастым. Бернична ел эшли алмадым. Савыгып, эшли башлагач, беренче эш хакыма мәчеткә кереп Коръән китабы сатып алдым. Укый белмәсәм дә, өйдә күз алдымда торсын дидем. Шул көнне үк мәдрәсә төзелешенә дә 100 сум акча биреп, эчемнән генә теләк теләдем: "Мәдрәсәгә кереп чыгарга насыйп булса иде!" Дүрт ел узгач шушы мәдрәсәгә кереп чыгарга гына түгел, анда дин гыйлеме алырга да насыйп булды. Аллаһы Тәгалә миңа гел ярдәм итеп тора. Эш урынымда да яхшы якка үзгәреш булды һәм мин, шуннан файдаланып, дин гыйлеме өйрәнергә ниятләдем. Җитәкчемнән эшне җайлап, мәдрәсәгә йөрергә рөхсәт сорадым. Ул мине хуплады гына. "Укырга беркайчан да соң түгел, теләгең булгач, рәхим ит!" –диде. Мин анда узган җәйдән бирле көн саен эшлим. Шулай да, вакыт табып, Аллаһы Тәгалә ярдәме белән, бик теләп, яратып, бер генә уку көнемне дә югалтмыйча, шатланып мәдрәсәгә йөрим. Каникуллар, яллар булганда бергә укый торган талибә һәм безгә гыйлем бирүче мөгаллим-мөгаллимәләрне сагынып килә. Җаныбызга, күңелебезгә тынычлык бирә торган урын ул мәдрәсә. Бирегә гыйлем генә түгел, ниндидер рәхәтлек, җиңеллек алырга дип керүчеләр дә бар. Бер ханым әйтә: "Шушында кереп утырып күңелемә тынычлык алам,"– ди. Чыннан да, әйтеп, аңлатып бетерерлек түгел андагы гүзәллекне, рәхәтлекне. Яшьлегебездә мондый нәрсәләр безнең төшкә дә кермәде, хәзер яшьләргә рәхәтләнеп дин гыйлемен үзләштерергә мөмкинлекләр күп. Я, Раббым, уйларыбыз ак, күңелебез пакъ, сүзләребез хак, зиһенебез саф, иманыбыз нык булсын. Аллаһы Тәгалә барчабызга да гомеребезне, сәламәтлекләребезне биреп, елларыбыз имин булып, шушы мәдрәсәдә үзебезгә, балаларыбызга, оныкларыбызга да гыйлем алырга язса иде. Амин!

***МӨНИРӘ НӘБИУЛЛИНА.***
***1 курс шәкерте.***

# Иманлы бала–нәсел күрке

**Бала туды... Һәрбер ата-ана баласының сау-сәламәт, бәхетле, шәфкатьле булып үсүен тели һәм көтә. Бу табигый хәл, кешенең гомере бик кыска, картаюга ул балаларның үзенә таяныч булуына зур өметләр баглый.**

Балаларыбызны дөрес, акыллы кеше итеп тәрбияләү өчен барыбызга да Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт кылуны тормышыбыз рәвеше итеп алырга кирәк. Нәрсә ул гыйбадәт? Гыйбадәт ул Аллаһы Тәгаләнең яраткан эшләренең, Ул риза булган сүзләрнең ачык яки яшерен эшләнгән эшләрнең атамасы. Намаз уку, дога кылу. Аллаһны һәрдаим искә алу, ата-анага яхшы мөнәсәбәт һәм башка шундый гамәлләр гыйбадәт булып санала. Яңа туган баланы тәрбияләгәндә, баланы имезергә алганда ана тәһарәтле булса, бисмилләһиррахмәниррахим кәлимәсен әйтеп имезә башласа, бүлмәдә Ихлас, Аятел –Көрси сүрәләре дә булса, бик күркәм булыр иде. Бирегә шайтан кермәс, балага фәрештәләр тәсбих әйтерләр иде, нәтиҗәдә бала нык иманлы булып үсәр иде. Революциядән соң, җитмеш ел буена, "Дин юк!"–дип,- тәкърарлап тордылар, нәтиҗәдә без ислам, Коръән юлыннан читләшкән идек. Әлхәмдүлилләһ, фидакарь әби-бабайларыбыз качып-посып булса да намазын укып, уразасын тотып, динне әлеге көннәргә кадәр китереп җиткергәннәр. Хәзер дөньялар үзгәрде: ябылган мәчетләр ачылды, хәтта мәдрәсәләребезгә кадәр бар. Әти-әниләргә, әби-бабайларга, укучы балаларга да дин дәресләрен өйрәнергә мөмкинлекләр күп, тик теләк кенә кирәк.

Алласызлыкның нәтиҗәсе буларак, дөньябызны алкоголизм, наркомания, фахишәлек басты, әллә нинди яман авырулар килеп чыкты. Әле моннан 50 ел элек кенә аракы кулланучы авылда бер-ике генә булса, хәзер аякка баскан баланың күбесе тәмәкене һәм аракыны авыз итәргә тырыша. Динебездә хәрам һәм хәләл дигән төшенчә бар. Хәрам Аллаһы Тәгалә катгый тыйган гамәл, Аллаһыдан куркып, хәрамнан тыелган кеше, күп саваплы була. Аракы эчү, наркотик куллану, дуңгыз итен ашау, урлау, гайбәт сөйләү , яла ягу һәм башка шундый эшләр - хәрам гамәлләр. Пәйгамбәребез Мөхәммәт (с. г. в.) әйтте: "Әгәр тәннәрегезне хәрам ризык белән җыйсагыз, кыямәт көнендә шушы тәннәрегез тәмуг утына ягулык булыр." "Әгәр балаларыгызның тәннәрен хәрам ризык белән җыйдырсагыз, үсеп җиткәч көчләре сезгә каршы борылыр." Тагын хәдис: " Балаларыгызны җиде яше тулгач намазга әмер итегез, әгәр ун яше тулгач басмаса, мәҗбүри бастырыгыз."

Хөрмәтле әти-әниләр, балаларыбызда Аллаһы Тәгаләгә ышанырга, Коръән кануннары буенча яшәргә омтылыш уятыйк. Ислам дине тәрбиясе алган балалар өчен, алар яннарыбыздан чыгып киткәч тә, борчылмыйбыз. Хәзер бит төрле начар секталар бар, яшьләрне шул оешмаларга тартырга тырышучы бик күп бозык адәмнәр барлыкка килде. Әгәр дә әти-әни баласын Аллаһы Тәгалә тыйганнарыннан тыелып, кушканнарын үтәп яшәргә, хәрамның хәрам икәнен, хәләлнең хәләл икәнен аңлатып үстерсә, балаларыбыз секталарга да иярмәс, башка бозыклыклардан да имин булырлар иде.

***МУРАТОВА ЛЕНА.***
***Олыяз авылы.***

**(Әлеге мәкалә конкурска язылды).**

## Сорау илә җавап

**–Намаз укучы мөселман алтын әйберләрне кия аламы?**

–Әлбәттә, юк. Пәйгамбәребез дә бу гамәлне тыйган. Ул бер кулына ефәк, икенчесенә алтын тотып, болай дигән: "Болар өммәтемнең ирләренә хәрам булды, ә хатын-кызларына хәләл булды",–дип әйткән. Алтынны йөртергә ярамаганы хакында тагын хәдисләр бар.

**–Ураза тоту ач тору гына түгел, ул дөрес булсын һәм кабул ителсен өчен нәрсә эшләргә кирәк?**

–Һәрбер гамәлнең дә шартлары, мәҗбүри эшләре бар, уразаның да бар алар. Ураза тоту акыллы, балигъ һәм сәламәт булган һәрбер мөселманга фарыз. Мосафирларга, күрем һәм нифас вакытындагы хатын-кызларга фарыз түгел. Уразаның нигезен ният һәм ашау-эчүдән, җенси якынлык кылудан тыелу тәшкил итә. Андый вакыт таң беленгәннән башлап, кояш баеганчы дәвам итә. Шушы вакытта ашау-эчүдән, җенси якынлыктан тыелырга кирәк.

**–Минем йөрәгем авырта һәм табиблар бала тапмаска киңәш итә. Хәзер мине димләргә ниятлиләр. Бу хакта булачак иремә әйтергә кирәкме?**

–Баланы табып үстерү ата-ананың төп бурычы булып тора. Әмма, саулыгыгызның корбаны беркемгә дә кирәкми. Һичшиксез, киләчәк тормыш иптәшегез сезнең сәламәтлегегез хакында белергә тиеш. Әгәр дә бу хәлне яшерәсез икән, ул киләчәктә барыбер ачылачак. Гаиләдә ир белән хатын бербөтен организмга әйләнә. Шулай да мин сезгә кабаттан тикшеренүләр узарга киңәш итәр идем. Чөнки еш кына беренче мәртәбә төгәл диагноз куюкатлаулы. Әгәр дә сезгә табиблар барыбер бала табарга киңәш итми икән, моның турында булачак ирегезгә әйтегез. Булачак тормыш иптәшегез чыннан да сезне ярата икән, сезнең белән калыр.

**–Мөслимәгә каш йолкырга ярамый дип ишеттем, бу хакмы?**

–Дөрес. Бу хакта бер хәдис бар. Әгәр дә аерым озын үсә торган каш бөртекләре сезнең кыяфәтегезне боза икән, бу очракта аны йолкырга була. Моны бары тик кашның рәвешенә зыян салмыйча эшләргә кирәк.

## Әнием истәлегенә...

Һәрбер көннең
һәрбер минутында
Түзеп булмый
моңсу уйларга.
Төннәр буе уйлап
ятканнарым,
Күчә хәзер шигъри
юлларга.
Нәни чакта
Баскан сәхнәсеннән,
Сиңа атап
шигырь сөйләдем:
“Алты балаң алты
яктан килеп,
Бәйләм, бәйләм
чәчәк китерсен.”
“Озак яшә, Әнием!”,–
димәдем...
Нинди булдык,
рәхәт китердекме?
Күңелемне борчый
мең сорау.
Сабыр, түзем,
газиз Әнкәемә,
Җәннәтеннән
насыйп итсен Ходай.
Тәүлекнең
һәрбер мизгелендә,
Сине генә
уйлап моңланам.
Дөньяларга кире
кайтсаң әгәр,
Сине сөеп, күреп
туя алмам.
Сине уйлап
өзгәләнә күңел,
Балаларың сине сагына.
Юклыгыңны
аңлап яшәү җиңел түгел,
Хәер доганнан,
Син, калдырма.
Бүген инде шигырь
бара алмый,
Бара бары изге догалар.
Ана куанычы
булып кала җирдә,
Тулы иманлы,
догачы балалар.
Әнием-бәгърем,
җаның тыныч булсын,
Каберләрең нурга
күмелсен.
Алты балаң
Сиңа дога кыла,
Савап булып
барып ирешсен.

***ХАҖИЕВА ӘЛФИРӘ,***
***мәдрәсә шәкерте.***
***Норма авылы.***

## Газетабызның алдагы санында басылган викторина җаваплары

1.Фил сүрәсендә. 2.Гали. 3.Ухуд тавы. 4.Туба агачыннан. 5. Тәхлил, тәхмид һәм тәкбир әйтеп. 6.Лут (г.с.), Нух (г. с.) хатыннары. 7.Та-Ха сүрүсе. 8. Җәбраил . 9. Сам, Хам, Афас, Канган. 10. Сәдака. 11.Әбүбәкер. 12.Бал, чишмә суы, сөт, шәраб.(Мөхәммәд сүрәсе, 15 аять).13. Пәрәвез, күгүрчен. 14.Ал–Саур. 15. Якуб (г.с.)

“Эрудитлар круизы”нда Мамадыш шәһәреннән Вәрис Гали яулады.

Кадерле укучыларыбыз, сезгә Ислам тематикасына кагылган яңа викторина сорауларын тәкъдим итәбез.

1.Күрмәгән төшне күрдем дип сөйләгән кешене, кыямәт көнендә нинди җәза көтә?
2.Кешеләрнең сүзен тыңлап торучыны кыямәт көнендә нинди җәза көтә?
3.Кайсы агачны Пәйгамбәребез мөселман белән чагыштырган?
4. Исмәгыйль (г. с.) хатынын Җөрһүм кабиләсеннән ала. Бу никахтан яңа кабилә барлыкка килә. Ул кабиләнең исеме ничек?
5. Башлангыч чорда Ислам диненең иң зур дошманы кем булган?
6. Мөхәммәд (с.г.в) бала чагында ук анда пәйгамбәрлек сыйфатларын танып алган руханиның исеме ничек?
7. Әлеге кешенең Исламга керүе мөселманнарга җиңеллек китерә һәм мөселманнарга Кәгъбәтулла-да намаз укырга мөмкинчелек бирә. Бу кешенең исеме ничек?
8. Намаз уку кайсы елда фарыз кылына?
9. Мөхәммәднең (с. г. в.) кайсы туганы пәйгамбәрлекнең 6нчы елында Ислам динен кабул итә һәм Ухуд сугышында шәһит китә?
10. Салих (г. с.) кайсы халыкка җибәрелгән?
11. Салих (г. с.) кешеләргә үзенең пәйгамбәрлегенә дәлил итеп нәрсә китергән?
12. Ибраһим (г. с.) кайда туган?
13.Гайсәнең (с. г.) икетуган абыйсын атагыз?
14.Җәһәннәм әһелләренең теше нинди зурлыкта булыр?
15. Пәйгамбәребез Мәдинә шәһәренә атланып килгән дөянең исеме ничек?

### *Мөселман балалар лагерена чакырабыз*

*Җәйгеканикулдәверендә* **МАМАДЫШ МӘДРӘСӘСЕНДӘ** *мөселман балалар лагере уздырылачак.* **Ир-егетләр өчен** *беренче смена: 6 июньнән 15 нче июньгә кадәр, икенче смена: 16 июньнән 25 нче июньгә кадәр дәвам итәчәк.* **Кызлар өчен** *беренче смена: 25 июльдән 4 июльгә кадәр , икенче смена: 5 нче июльдән 14 июльгә кадәр дәвам итәчәк. Лагерьга район авылларыннан да балалар килүе көтелә. Лагерь барышында балалар Ислам диненең нигезләре белән танышачак, төрле спорт уеннарында катнашачак, тарихи урыннарны зыярат кылачак.*

# Мамадыш мәдрәсәсенә рәхим итегез!

Мәктәпләрдә һәм дини укыту – тәрбия йортларында эшләү, Аллаһы Тәгаләнең чын динен хаклау һәм үстерү максатыннан чыгып Татарстан Җөмһүрияте Мөселманнары диния Нәзарәте каршындагы Мамадыш мәдрәсәсе алдагы уку елына шәкертләр туплый.

Белгечләр әзерләү көндезге уку рәвешендә алып барыла. Мәдрәсәгә тулы булган яки тулы булмаган урта белемле, яше 14-15 яшьтән дә ким булмаган егетләр кабул ителә. Шәкертләр мәдрәсә тулай торагында яшәү урыны һәм көненә 3 тапкыр ашау-эчү белән тәэмин ителәләр. Мәдрәсәдә белем алучылар шәкерт статусына ия булалар. Укыту планын һәм программасының барлык таләпләрен үтәгән, чыгарылыш имтиханнарын уңышлы тапшырган шәкертләргә квалификация комиссиясе карары нигезендә тиешле белгечлек алу турында шаһәдәтнамә бирелә. Укырга керү өчен кабул итү комиссиясенә түбәндәге документларны тапшырырга кирәк:

•Белем турында таныклык.
•086 – формасында сәламәтлек турында белешмә.
•Характеристика.
•Паспорт күчермәсе.
• 3х4 үлчәмендә 4 фотосүрәт.

Намаз укырга өйрәнергә һәм дини белемне үзләштерергә теләүчеләр өчен мәдрәсәдә кичке уку бүлеге һәм читтән торып уку бүлеге эшли.
“БИШЕКТӘН АЛЫП ЛӘХЕТКӘ КАДӘР ГЫЙЛЕМ АЛЫГЫЗ”.

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең Бөек исемнәре булганга күрә, аны саклап тотуыгыз сорала**

**Баш мөхәррир: Хәбибуллин А.М. Мөхәррир урынбасары: Хәбибуллина Э.Р.**
**Дизайн һәм верстка: Мингалиева Ф.Н. Җаваплы сәркатип: Спиридонова А.С.**
**Безнең адрес: Мамадыш шәһәре, Муса Җәлил урамы,8/28. mamadysh-medrese@mail.ru. Газета “Татмедиа” ААҖнең Мамадыш муниципаль районы”Нократ” мәгълүмат-матбугат филиалында басылды. Тираж татар телендә 100 данә.**